# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Зирекле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 31 мартыннан № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгы карары белән «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авылы җирлегендә гражданнар җыеннарын хәл итүгә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2024 елның 20 мартындагы 2 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенен Зирекле авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 30 октябрендәге 2023 елның 2 номерлы карарына, гражданнар җыенының 2024 елның 31 мартында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 30 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыеннары карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм аларны урнаштыру, скважина бораулау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәй көне территорияне чүп үләннәрдән чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, тирәлеген төзү ремонтлау (куакларны кисү, агач төпләрен казып алу, теяү һәм озатып җибәрү, агач аудару, агач сейрәп чыгу, агачны эшкәртү, ботакларны утильләштерү, бульдозер белән грунт эшкәртү, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 513 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә җыенында катнашучы гражданнардан 287 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенының 287 катнашучысы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авылы җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес.

2. Сорауны карар буенча тануны:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 30 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыеннары карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм аларны урнаштыру, скважина бораулау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәй көне территорияне чүп үләннәрдән чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, тирәлеген төзү ремонтлау (куакларны кисү, агач төпләрен казып алу, теяү һәм озатып җибәрү, агач аудару, агач сейрәп чыгу, агачны эшкәртү, ботакларны утильләштерү, бульдозер белән грунт эшкәртү, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).» - кабул итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет»: https://pravo.tatarstan.ru мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет»: https://novoseshminsk.tatarstan.ru/, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга, Зирекле авылының Ленин урамы, 53 йорт, Ленин урамы, 68 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында, Яңа Чишмә муниципаль районы порталында кабул ителгән көннән алып 10 эш көне дәвамында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Җ.Г. Гайфетдинов